**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Сапалы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар
Сараланыавылы, Татарстан урамы, 17
нчейорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**2019 елның 1 ноябре** **159номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге составына керүче Татар Сараланы торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 19 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге- «2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге составына керүче Татар Сараланы торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне:

- Татар Сараланы авыл җирлеге составына керүче Татар Сараланы торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?"-дигән сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган, 267 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 225 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында 225 катнашучы «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге составына керүче Татар Сараланы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Карадули торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татар Сараланы авыл җирлеге составына керүче Татар Сараланы торак пунктын урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?»- соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татар Сараланы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче- И.Ф.Мубаракшин

Татар Сараланы авыл җирлеге Советы рәисе - И.Ф.Мубаракшин